УДК 821.512.145

***А.С. Исмакова***

# КЛАССИК СТИЛЬ: АБАЙҺӘМ ПУШКИН

Каждая национальная литература в своем развитии достигает той поры, когда в ней может появиться такой гений, творчество которого надолго становится мерой ее дальнейшей судьбы. В статье автор ведет речь о творчестве двух таких гениев: об Абае и Пушкине. При этом в исследовании речь идет не только о целостном восприятии их художественного мира. Литература классического стиля раздвигала границы прежней литературы, как и само представление о предмете и ее возможностях. Авторы классического стиля не декларативно, но практически приобщают литературу к государственным проблемам. Автором проводятся параллели в вопросах творческих достижений классиков Абая и Пушкина, они оцениваются не только как классики литературы, но и как государственные деятели в искусстве, ибо они в своих художественно-философских размышлениях поднялись до вопросов национальный судьбы народа.
**Ключевые слова:** национальная литература, Абай, Пушкин, художественно-философские размышления, классик, наионально-исторический контекст.

Each national literature in its development reaches the time when such a genius can appear in it, the work of which for a long time becomes the measure of its further destiny. In the article, the author talks about the work of two such geniuses: Abai and Pushkin. At the same time, the study is not only about the holistic perception of their artistic world. Literature of the classical style pushed the boundaries of previous literature, as well as the very idea of the subject and its possibilities. The authors of the classical style do not declaratively, but practically, attach literature to state problems. The author draws parallels in matters of the creative achievements of the classics of Abai and Pushkin, they are considered not only as classics of literature, but also as statesmen in art, for in their artistic and philosophical reflections they raised the issues of the national fate of people.
**Key words:** national literature, Abai, Pushkin, artistic and philosophical reflections, classic, national historical context.

Ни өчен Гете, Петрарка, Байрон, Шекспир, Пушкин һәм Абай заманчалыгын һичкайчан югалтмый? Моның сере нәрсәдә? XX гасыр башында Казакъстанда совет хакимияте ни өчен Абайны «заманчалык корабыннан» төшереп калдырырга теләде? Ни өчен XX гасыр башында күп кенә язучылар, «Алаш» партиясе эшлекләләре Абайның сәнгати мирасын яклауны үзләренең бурычы дип санадылар? (А. Бокейханов (1904), А. Байтурсынулы, М. Дулатов, Ж. Аймауытов, М. Ауэзов, М. Жумабаев, С. Торайғыров, Б. Кулеев, И. Жансугуров мәкаләләрен кара). 1913 елда А. Байтурсынулы «Қазақ» газетасында «Қазақтың бас ақыны» дигән баш астында үзенең программ мәкаләсен бастырып чыгарды һәм XX гасыр башындагы бәхәсләргә нокта куйды.

Казакъ совет әдәбияты Абайны өйрәнүне исәпкә алмыйча үсте. А. Байтурсынулының «Әдебиет танытқыш»ы (1926) фәнни әйләнешкә 1989 елда, авторның сәяси реабилитациясеннән соң гына кайтарылды.

Совет чоры дәреслекләрендә Абай, И. Алтынсарин һәм Ч. Вәлиханов белән бер рәттә, «мәгърифәтче-демократ» буларак тәкъдим ителә. Бу «мәгърифәтчеләрнең» исемнәре казакъ мәдәнияте күгендә бер дәрәҗәдә балкый.

1989 елда А. Байтурсынулының «Әдебиет танытқыш» дип исемләнгән мәкаләсе һәм «Қазақтық бас ақыны» – «Казакъларның баш шагыйре» [Байтұрсынұлы, 2003] яңадан басылып чыга. Бу очракта, Пушкин, Гете, Шекспир хакында сөйләгәндәге кебек, чишмә башы турында сүз бара. А. Байтурсынулы тугыз биттә әлеге фәнни нигезләмәне ачык һәм ышандырырлык итеп ача һәм исбатлый. Әдәбият белгече Абайның «тиянақты – үлгілі» – үрнәк классик поэзиясе турында сөйли. Соңрак, Абай иҗатына нисбәтән, «классик» сүзен Кудайберген Жубанов та куллана (1933). «М. Горький исемендәге Дөнья әдәбияты институты. Әдәби стиль теориясе» басмасының беренче томы да (1976) классик стильгә багышлана [Теория литературных..., 1976].

А. Байтурсынулы, М. Дулатов, Ж. Аймауытов һәм М. Ауэзов мәкаләләрен тагын бер кат укып, П.В. Палиевскийның классик стиле турында И.Ю. Подгаецкаяның «Пушкин как классическая мера русского стилевого развития» дигән фундаменталь тикшеренүләренә мөрәҗәгать иттем. 1980 еллар ахырында гына безгә кабат кайтарылган XX гасыр башы Абайны өйрәнү фәне бик тә заманча, һәм Абайны һәрдаим казакъ әдәбиятының төп ориентиры сыйфатында бертавыштан танып, әдип мирасының гармониясен һәм үзенчәлекләрен ачып биргән икән.

Чыннан да, һәрбер әдәбият тарихында исемнәре мәңгелек дан символы, милли әдәбият җәүһәрләренең бөеклеген раслаучы дәлил буларак кына түгел, ә сүз сәнгате идеалын үз эченә алган күренеш буларак та кала торган язучылар бар. Рус әдәбиятында ул – Пушкин, итальян әдәбиятында – Петрарка, испан телендә – Лопе де Вега, немецларда – Гете, француз әдәбиятында – XVII гасыр классицистлары, казакъ әдәбиятында – Абай.

Милли һәм тарихи контекстларда үзгәлекләр булуга карамастан, алар башка классиклардан нәрсәсе белән аерылып тора соң? Дәвамчылары аларны әле үз заманыннан төшереп калдыра, әле аларның әсәрләрендә барысы да гасырлар буена алдан билгеләнгән дип игълан итә. Телиләрме-юкмы, әмма алар үзләрен иң элек әлеге исемнәр белән үлчи, чагыштыра. Чыннан да, бу феноменнар сәнгатьчә итеп, ягъни «асыл сөз бен» (А. Байтурсынулы) үз халкының әхлакый йөзендәге иң мөһим нәрсәләрне чагылдыра алды. Пушкин турында бөтен нәрсәнең «чишмә башында торучы» дип сөйлиләр. Француз әдәбиятында «барлык юллар очрашкан урын»ны ватандашлары Лафонтен һәм Расин иҗатында тапканнар, ә Лопе де Вега, бертавыштан, испан әдәбиятына нигез салучы буларак танылган.

Һәр милли әдәбият үзенең үсешендә иҗаты шушы әдәбиятның киләчәк язмышын билгеләячәк даһи туарга мөмкин булган чорга җитә. Әмма шуның белән бергә сүз нормативлыкның формаль ягы турында бармый. Аларга болай гына иярү мөмкин түгел. Бары аларның сәнгати дөньясын тулаем кабул итү турында гына сүз алып барырга мөмкин.

Гейне Шекспирда «иксез-чиксез күптөрлелегендә бөтен дөньяны, бөтен галәмне», замандашлары Лопе де Вега әсәрләрендә «һәр яктан җитеш дөньялар»ны күргәннәр, Гоголь Пушкинның «таң калдыргыч дөньясы» турында язган. Барлык бәяләмәләрдә дә классик авторларның кояш белән чагыштырулары кабатлана: «Рус поэзиясе кояшы» (Пушкин), «болытлар астыннан чыккан кояш» (Меринг Гете турында), «рухи кояш» (Гейне Шекспир турында). А. Байтурсынулы Абай турында, аның нигезе, казакъ әдәбиятының фундаменты буларак сөйли, ул чын хакыйкать һәм яктылык бирә, ул матур әдәбиятка югары рухият китерә. «Хақиқатты хақиқат қалыбында, тереңді терең қалыбында жазған». М. Жумабаев соңрак: «Хакім Абай», – дип белдерә.

Гадилек, табигыйлек, стиль гармониясе классик стиль тарафдарларына үзләренең милли алдан билгеләнешен аңларга мөмкинлек бирде. Алар милли һәм дөнья әдәбиятының бөтен тәҗрибәсен үзләштерделәр һәм шуның аркасында гына гасырларга күчәрлек эстетик әһәмияткә ия булганнарының синтезын булдырдылар.

А. Бокейханулы һәм А. Байтурсынулы билгеләп үткәнчә, Абай хәзерге заманга актив катнашырга мөмкинлек бирә торган эчке бәйсезлеге белән дә җәлеп итә. Нәкъ менә шундый эчке бәйсезлекне һәм югары рухиятне эзләү Абайны өйрәнүчеләрнең беренче буынына әдипнең сәнгать тәҗрибәсен тирәнтен аңларга булышты. Алар Абай стилендә шигъри сүзнең киеренке ассоциативлыгын: «сөзі аз, мағынасы көп, терең», күпкатлылыгын, күпмәгънәлелеген һәм тирәнлеген билгеләп үтәләр: «не нәрсе жайынан жазса да Абай түбірін, тамырын, ішкісырын, қасиетін қармай жазады».

А. Байтурсынулы Абайның сүз өстеннән аерым хакимлеккә ия булуын ассызыклый: «Нәрсенің сырын, қасиетін біліп жазгансоң, сөзінің бәрі де халыққа тіреліп, оқушыларының біліміне сын болып, емтихан болып табылады». Ул гына да түгел: «Хақиқатты тануға, тереңнен сөйлеуге, бойына біткен зеректіктің үстіне, Абай әртүрлі Европа біліми елерінің кітаптарын оқыған», ягъни үз чоры дөнья әдәбияты тәҗрибәсен исәпкә алмый торып, Абай без бүген аның мирасы дип атаган хәзинәне тудыра алмас иде.

Нәрсә соң ул стиль? Ул: «әсәрнең эчтәлек формасындагы барлык элементларның (образлар системасының, сәнгати сөйләм, жанр, композиция, фабула, ритм, интонациянең эчке бәйләнешләре) бердәмлеге һәм бөтенлеге гәүдәләнеше буларак сәнгатькярнең иҗади индивидуальлеге һәм аның сәнгати фикер формалары чагылышы [Теория литературных..., 1976]. Мондый һәр стиль элгәреге милли стиль үсеше тәҗрибәсенә таяна һәм аны яңача дәвам итә. Бу уңайдан Абайның

классик стиле – тотрыклы һәм милли мәдәнияттә үскән уйлау, хис итү, язу, һәм үз чынбарлыгы, кешенең андагы урыны турында фикер йөртү һәм бәяләү манерасы да. Абай стиле казакъ әдәби теленең бик зур тәҗрибәсен, халыкның мөһим фикерләрен һәм психологиясен генә түгел, ә бәлки күп дәверләр алдан үз милләтенең әдәби үсешен дә билгеләде.

Классик стиль тарафдарларының иҗаты милли әдәби тел урнашу белән дә бәйле. Ф.М. Достоевский Пушкин турында болай диде:

«Пушкин первый заговорил самостоятельным и сознательным русским языком». А. Байтурсынулы: «Абай сөзі өз заманындағы ақындардың сөзінен оқшау, олардың сөзінен үздік, артық» («Абай сүзе үз заманындагы шагыйрьләр сүзеннән төгәллеге һәм көтелмәгәнлеге белән аерылып тора»).

Пушкинның классик стиле турында Ю.Н. Тынянов болай дип язган: «Слово стало заменять у Пушкина своей ассоциативной силой развитое и длинное описание», что его слово «многосмысленно» [Тынянов, с. 131]. Гармония (үйлесімілік, реттілік), бөтеннең берлеге (тиянақтылық), Абай стиленең гадилеге һәм табигыйлеге А. Байтурсынулы мәкаләсенең төп темасы булып тора.

Классик стиль дәвере – ул әдәбиятның милли үзаңы үскән чор да. Классик стиль вәкилләре әдәбиятка дөнья әдәбияты контекстын исәпкә алып, яңа үлчәм белән якын килә. Нәкъ менә немец классик стилен булдыручы Гетеның «Weltliteratur» төшенчәсен фәнни әйләнешкә кертүе очраклы түгел. Пушкин, үзенең әсәрләре белән беррәттән, үз чоры рус әдәбияты әсәрләрен бәяләгәндә дә, аларны һәрвакыт дөнья әдәбияты казанышлары белән чагыштыра. Шуңа күрә Пушкин, немец, инглиз, француз әдәбиятлары тәҗрибәсен күздә тотып, «ученость, политика и философия еще по-русски не изъяснялись; метафизического языка у нас вовсе не существует», дип әйтә алган. Абай да үзенең элгәрләренә тәнкыйди якын килгән: *Шортанбай, Дулат пенен Бұқар жырау, Өлеңі бірі – жамау, бірі – құрау.* Абай шагыйрьнең укучы алдында аерым бер җаваплылык тоюын таләп итә:

*Ескі бише отырман бос мақалдап,*
*Ескі ақынша мал үшін ғұрман зарлап.*
*Сөз түзелді, тыңдаушы, сен де түзел,*
*Сендерге де келейін енді аяңдап.*

Пушкин да укучыга аерым игътибар белән карый. «Московский вестник» наширенә язган хатларында ул: «Не вижу никакого стыда угождать ей (публике) и следовать духу времени», – дип яза. Абай исә шагыйрьнең җаваплылыгы турында гына әйтеп калмый, ә укучының ролен һәм аның сәнгати бербөтен булдыруда катнашуын ассызыклый. Ул аның зәвыгы үзгәрүне дә искә төшерә: һәр шагыйрь моның белән исәпләшергә тиеш. Абайның бу укучысы нинди соң? Аның турында шагыйрь болай ди: *Бұл сөзді тасыр ұқпас, талапты ұғар. Көңілінің көзі ашык, сергек үшін….* Яисә: *…Өлеңі бар, өнерлі, інім сізге…*

Әлбәттә, ул талантлы, ачык күңелле, ярдәмчел, шуңа күрә рухы белән шагыйрьгә һәм шигърияткә якын кеше. Абай үз әсәрләрендә мөрәҗәгать иткән укучы әнә шундый.

Классик стиль әдәбияты предметның үзе һәм аның мөмкинлекләре турындагы күзаллауларның да, элеккеге әдәбиятның да чикләрен киңәйтте. Нәкъ менә Гетеның бөтендөнья әдәбияты дәвере турында сөйләве юкка түгел, Абай шулай ук югары иҗекнең аерым ролен, әдәбиятның асылын билгели: *Өлең сөздің патшасы, сөз санасы. Я*ки тагын: *Өзгега көңә, лім тоярсың. Өлеңді кайтып киту?* Классик стиль авторлары әдәбиятны декларатив рәвештә түгел, ә гамәли яктан дәүләт проблемаларына алып керә. Подгаецкий сүзләренә караганда, Петрарка, Лопе де Вега, Пушкин сәнгатьтә тулаем дәүләт эшлеклеләре булалар, чөнки сәнгати-фәлсәфи фикерләүләре белән милли язмыш мәсьәләләрен дә колачлыйлар («Борис Годунов»).

Абайның лирик әсәрләренең үзәген һәм «Ғақлия» прозасының төп темасын милли язмыш проблемалары тәшкил итә. Бу турыда ул иң элек шигырьләрендә белдерә:

*Қалың елім, қазағым, қайран жұртым,*
*Ұстарасыз аузыңа түсті мұртың.*
*Жаксы менен жаманды айырмадың,*
*Бірі қан, бірі май боп енді екі ұртың.*

Шагыйрьне халыкның таркаулыгы куркыта:

*Бас басына би болған өңкей қиқым,*
*Мінеки, бұзған жоқ па елдің сиқын.*

Элгәрләреннән аермалы буларак, Абай «Ғақлия» текстын үзенчәлекле итеп оештырып, эстетик ачыш ясый. «Автор – герой (яки нәрсә турында сөйләнсә – шул) – укучы (тыңлаучы)» өчпочмагын исәпкә алу әсәр структурасында бу тавышларның мөстәкыйль яшәешенә яңа мөмкинлекләр ача. Өстәвенә һәр «Сүздә» шагыйрь тыңлаучының мәрхәмәтлелеге яки мәрхәмәтсезлеге, ризалыгы яки ризасызлыгы белән эшли [Исмакова, с. 56].

Абай рус әдәбиятыннан тәрҗемә итеп кенә калмый, үз казанышы сыйфатында тоеп, дөнья әдәбияты тәҗрибәсенә иркле таянып иҗат итә. Һәм бу бик тә мөһим. Шуңа күрә аның классик стиле үзендә стиль бөтенлеген берләштерә. Мондый стиль казакъ әдәбиятының чикләрен, аның гадәти мөмкинлекләрен киңәйтә. Әйтик, Абай әдәбиятны дәүләт проблемаларына тарта, «Ғақлия»дә ул милли язмыш мәсьәләләре югарылыгына күтәрелә, бу темаларны үзенең әдәбифәлсәфи уйлануларында яктырта, бер үк вакытта аларны лирик әсәрләренең үзәге дә итә. Абайның классик стиле шул заманның барлык язма стиль формаларын колачлый: философияне, чыганакчылыкны, очеркларны.

Шагыйрь «Ғақлия»сенең стиль ягыннан казакъ прозасының башлангычы булуы очраклы түгел. Абай «Ғаклия»не язганнан соң,

элек казакъ әдәбиятыннан читтәрәк булган прозаик формалар беренче планга чыга, алар шигърият белән чагыштырырлык статус ала. Әмма иң элек поэзиядәге классик стиль аларга кыскалык һәм ачыклык бирә, мәгънә бер фраза эченә туплана, ягъни элек шигъри стиль тарафыннан эшләнгән принциплар эшкә җигелә.

Заманча әдәбиятның гына түгел, үзеннән элгәренең дә (үзенеке һәм чит) күптөрлелегеннән Абай милли әдәбият рухына аеруча туры килгәнне сайлап ала. Моңа бәйле рәвештә һәр милли классик стильнең эстетик нәтиҗәсе (аның дөнья әдәбияты контекстындагы урыны күзлегеннән караганда) – авторларның үз халкының рухын чагылдыручы буларак дөнья әдәбияты тарихына керүе. Дөнья әдәбияты фонында Абай иҗаты – казакъ әдәбиятында милли «акцент»ның иң югары чагылышы.

«Мәңгелек» хакыйкатьләргә төшенүнең Абай өчен беренче урында торуы гаҗәп түгел. Алар, билгеле булганча, барыннан да элек фундаменталь текстларда теркәлгән. Абай өчен иң мөһиме – Коръән.

*Әуелі аят, хадис – сөздің басы,*
*Қосарлы бәйіт сымал келді арасы.*
*Қисынымен қызықты болмаса сөз,*
*Неге айтсын пайғамбар мен оны Алласы.*

Соңгы юлларда Абай үзенең бу турыдагы күзаллауларын конкретлаштыра кебек:

*Ынсап-ұят, ар-намыс, сабыр, талап,*
*Бұларды керек кылмас ешкім қалап.*
*Терең ой, терең ғылым іздемейді,*
*Өтірік пен өсекті жұндей сабап.*

Беренче һәм соңгы юлларда шагыйрь әдәби иҗатның мәгънәсен һәм асылын аныклый, бәйрәмчә яшәү рәвешен аңа каршы куя. Абай сүз өстеннән аерым хакимлеккә ия. Ул даһи гадилеккә, без инде ачыклаганча, сүзнең семантик мөмкинлекләреннән мөмкин кадәр күбрәк файдалану аша ирешә. Абайның ике-өч шигъри юлында тулы бер картина урнаша, яки бер юл шулкадәр күп мәгънәле ки, ул үзенең ассоциатив көтелмәгәнлеге белән тетрәндерә: *Ішім өлген, сыртым сау* (Мин тышкы яктан мин исән, ләкин эчтән – үле). Чынга ашмаган хыяллар һәм җимерелгән планнар турында роман язу өчен шушы бер юл да җитә.

Классик стильнең барлык вәкилләре дә башка әдәбиятлардагы үз элгәрләренә аерым игътибар бирә. Билгеле булганча, Пушкин Шекспир һәм Гете тәҗрибәсенә мөрәҗәгать иткән, Петрарка – Гораций һәм Вергилийгә; Гете – Шекспирга, Абай – Пушкинга, Гетега һәм классик Шәрык поэзиясенә. Абай асылдан читкә алып китүче күпсүзлелектән, матур сүз әйләнмәләреннән кача. Казакъ толгауларының катлаулы-тантаналы стиле һәм акыннарның төгәл, әмма эпитетларга чорналган (жанр законы буенча) диалоглары классик

шагыйрьнең яңа эстетик таләпләрен канәгатьләндерә алмый. Ул казакъларның бер телдә Аллаһка дога кылуын, икенче телдә балаларын әрләвен, өченче телдә кичләрен тарихи дастан һәм хикәяләрне башкаруын ачык күрә. Абай үз иҗатында бу телләрне үзара якынайтып кына калмый, ә алар арасындагы аерманы да кыскарта.

Шигърияттә классик стильгә хас гадилек һәм табигыйлекнең тагын бер үзенчәлеге – мондый шигырьләрнең «прозаны хәтерләтүе». Толгау үзенең тантаналы стиле белән көндәлек сөйләм теленең табигыйлегенә якынайган кебек була.

Классик стиль үз чоры әдәбиятының төрле юнәлештәге тенденцияләрен берләштергән. Абай стиле толгауларның югары стиле белән акыннар, җырчы шагыйрьләр поэзиясе арасындагы урталыкны таба. Абай шигырьләренең җиңел җырлануы һәм истә калуы да очраклы түгел, әмма аларның мәгънәсе кабат-кабат үзләренә әйләнеп кайтырга мәҗбүр итә. Төгәл сүзгә омтылып, шагыйрь әдәби булмаган, башка чынбарлыкны да үзләштерергә омтыла. Гадилек һәм табигыйлек эзләү шагыйрьне «қарасөз»гә, гади гадәти сүзләргә китерә. Аның шигырьләре сөйләм ритмын сөйләм теле ритмы белән якынайта.

Бу уңайдан А. Байтурсынулының Абай шигырьләрендә ритмның бозылуы турындагы искәрмәсен искә төшерү зарур. Хәзер инде проза шагыйрьгә тыңлаучыларның игътибарын (әсәрнең) асылыннан читкә юнәлтми торган иң табигый сөйләп бирү формасы булып тоела. Шагыйрь иҗатының икенче яртысында проза беренче планга чыга: *Мен жазбаймын өлеңді ермек үшін...* (Тик торганнан гына шигырь язмыймын...) Шигъри өлгергәнлек киңрәк, тәфсиллерәк тасвирламалар таләп итә кебек тоела. Ә моны прозада гына гамәлгә ашырырга мөмкин. Шагыйрь үзенең эчке иҗат юнәлешен бер җөмлә белән әйтеп бирә: *Түбі терен сөз артық бір байқарсыз.* Аның өчен сүз генә түгел, ә аның тирән мәгънәлелеге мөһим. Шул ук вакытта шагыйрь һәрвакыт үзенең тыңлаучысын истә тота, аңа ышана гына түгел, башкалардан да аерып куя.

Белгечләр классик стильнең тагын бер үзенчәлеген – аның үтә нык филологик булуын билгеләп үттеләр. А. Байтурсынулы бу уңайдан болай дип ассызыклый: «Абай өлеңгеб асқа көзбен қарап, басқа құрмет, ықыласпен күтіп алып, төрт ұгіл тақтан орын берген». Чөнки: «Абайдың өлең жайынан жазған сөздерінде сыншылығы, өлең жаксы болуга не керектігін білетіні де көрініп тұр». А. Байтурсынулы Абайның аерым бер филологик сизгерлеккә ия булуы турында яза: «Сөз жазатын адам әрі жазушы, әрісыншы боларға керек. Сөздің шырайлы, ажарлы болуына ойдыңше берлігі керек. Үнамды, орынды, дәмді болуына сыншылдық керек. Мағыналы, маңызды болуына білім керек. Абайда осы үшеуі де болған» [Байтұрсынұлы, б. 157 – 158].

А. Байтурсынулы классик терминын кулланмый гына аңа аңлатма бирә: «Абай көсем, ұлгі шыгарып, өнеге жайгыш болган. Абай өлең жаксы болуға керек шарттардың бәрін білген. Сондықтан өлеңі қай тарапынан болса да толық».

Абай да, Пушкин кебек үк, – прозаик текстлар авторы. Классик стильгә хас гадилек һәм табигыйлекнең бер билгесе, – инде билгеләп үтелгәнчә, авторлар иҗат иткән шигъри әсәрләрнең «табигатьне хәтерләтүе»ндә. Шуңа бәйле рәвештә Карамзинның «Евгений Онегин» турындагы «Бу (әсәр) – проза буларак бик матур», дигән сүзләрен искә төшерү урынлы булыр. Классик чорга кадәрге проза әдәбиятның үзәгеннән читтәрәк тора кебек тоелса, хәзер ул беренче планга чыгарыла, шигърият белән чагыштырырлык статус ала. Шул ук вакытта классик стиль, барыннан да элек поэзиядә расланып, прозага кыскалык һәм төгәллек кертә, мәгънәне бер фраза эчендә туплый, ягъни поэтик стиль тарафыннан эшләнгән принципларны куллана. Бу уңайдан Л.Н. Толстойның «Капитан кызы» һәм «Белкин повестьлары» турындагы фикере күпләргә билгеле: ул аларның җитәрлек дәрәҗәдә төгәл булмавын әйтә. Безнең әдәбиятчылар «Ғақлия» не һәрвакыт саклык белән генә анализлыйлар, әмма аның мөстәкыйль, тәмамланган прозаик-фәлсәфи цикллар булуын бертавыштан таныйлар.

Дөньяны классик зиһенгә алу чынбарлыкны бербөтен буларак үзләштерүнең аерым бер ысулы белән характерлана. Классик стиль авторларына нәкъ менә шул милли әдәбиятларның төп темаларын алдан ук белергә мөмкинлек бирде. Ф.М. Достоевский үз һәм чордашлары иҗатында дәвер мәсьәләләренең чишмә башын Пушкинда тапкан: «Ведь и мы к современным вопросам пришли через Пушкина, ведь и для нас он был начало всего, что теперь есть у нас». Абайга нисбәтән А. Бокейханулы, А. Байтурсынулы, Ж. Айматулы, М. Дулатулы, М. Ауезов һәм М. Жумабаев мәкаләләрендә дә шул хакта ук әйтелә.

Абай лирик әсәрләрендә һәм бигрәк тә «Ғақлия»дә тәртипкә салынмаган көндәлек тормышны эзлекле итә, логик яктан тикшерелгән бөтен текст тудыра. Бу уңайдан А. Байтурсынулы болай дип яза: «Абайдың асылын танып, дұрыс баға берген нәрсесі жалғыз өлең емес. Көп нәрсені Абай сөз қылған, сол сөздерінің бәрінде де Абайдың әр нәрсенің асылын танығаны, білгені көрінеді. Абайдың өлеңдері казақтың басқа ақындарының өлеңінен үздік артықтығы әр нәрсенің бергі жағын алмай, арғы асылынан қарап сөйлегендіктен… Басқа ақындар аз білімін сөздің ажарымен толтыруға тырысқан. Абай сөздің ажарына қарамай, сыпайылығына қарамай, әр нәрсенің бар қалыбын сол қалыбыншадұрыс айтуды сүйген» [Байтұрсынұлы, б. 160].

Классик авторлар кешенең фаҗигале хәл-халәтен сурәтләгәндә, модернистик һәм постмодернистик әдәбиятка хас булганча, чарасызлыкны һәм өметсезлекне тулаем ачмыйлар. Классик әдәбият психологизмы шәхси түгел, ә гомуми эмоцияләргә басым ясый. Пушкинда да кискенлек юк, ул фаҗигалы вакыйгаларны фәлсәфи төшенү белән алыштырылган (Кечкенә фаҗигалар). Билгеле булганча, Ф.М. Достоевский «өлгергән җан тынычлыгы»н Пушкинда күргән. Абай поэмаларында һәм хәтта улы Абдрахман истәлегенә багышланган лирик

искә алу циклларында да уңай форма, фаҗигалылыкны ялангачландыру түгел, киресенчә, фәлсәфи-сәнгати төшенү өстенлек итә.

Фаҗигалылыкны бирүдә Абай үзенең элгәрләреннән вакыйгаларны фәлсәфи аңлауның көчәюе белән дә аерылып тора. Аңа рухның җитлегүле тигезлеге хас. Шагыйрь, билгеле булмаган, томанлы хис-тойгыны объектив аңлатырга, аның асылына төшенергә омтыла. Абайның *Сабыр қылсаң кереті* дигән сүзләре гомуми законнар барлыгын искә төшерә, бу, ахыр чиктә, әйберләрнең тәртибен аңлата һәм гармонияләштерә. Абай атеист булмаган, әмма ул, Бухар-жырау кебек үк, әйләнә-тирәдәге вакыйгаларның аңлатмасын нәкъ менә Коръәндә (*Алланың өзі де рас, сөзі де рас*) таба. Гомумкешелекнең мәдәни текстлары булган Тәүратта, Васыятьләрдә, Библиядә, Коръәндә гомум законнар аңлатып бирелә, аларны тану хәзерге яшәешне аңлап кабул итәргә мөмкинлек бирә. Бу җәһәттән без толгаулардагы рефлексив традицияләрнең Абайның классик стиленә күчүен күрәбез.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, Абай казакъ әдәбиятында беренче тапкыр сәнгатьнең социальлеге эстетикасын гамәлгә ашырды. Ул үз укучысына вакыйгаларда катнашучы итеп карый, аның үзен аңлавына һәм хуплавына ышана. Аудиториягә юнәлеш тоту Абайга зур фәлсәфи проблемалар турында фикер алышу җәелдерергә ярдәм итә. Ул *айтушы мен тыңдаушы, мыңмен жалғыз алыстым, акымақ көп, ақылды-аз* дигәндә, иң элек ул үзенең тыңлаучысын күз алдында тота:

*Базарға, қарап тұрсам, әркім барар,*
*Іздегені не болса, сол табылар.*
*Біреу астық алады, біреу маржан,*
*Әркімге бірдей нәрсе бермес базар.*

*Әркімнің өзі іздеген нәрсесі бар,*
*Сомалап ақшасына сонан алар.*
*Біреу ұқпас бұл сөзді, біреу ұғар.*
*Бағасын пайым кылмай аң-таң қалар.*

*Сөзді ұғатын осы күнде кісі бар ма?*
*Демеймін жалпақ жұрт қабірдей жағар.*
*Жазған соң жерде қалмас тесік моншақ,*
*Біреуден-біреу алып елге тарар.*

*Бір кісі емес жазғаным, жалпақ жұрт қой,*
*Шамданбай-ақ, шырақтар, ұқсаң жарар.*
*«Ит маржанды не қылсын» деген сөз бар,*
*Сәулесі бар жігіттер бір ойланар.*

Бу шигырендә шагыйрь шигъри иҗатның эчке асылын ачып сала. Шагыйрь үз укучысын *сәулесі бар жігіттер* (якты, нурлы кешеләр) итеп тасвирлый, шул рәвешле аларны көйсез һәм тотрыксыз халык төркеменнән аерып куя (*жалпақ жұрт*). Шагыйрь Абай үзенең йөрәгенә якын, иҗатташлыкта булышучы фикердәш тыңлаучысын социаль яктан аера.

XX гасыр башы чынбарлыгында да, әдәбиятта да социаль проблемалар алгы планга чыккач, классик стильдән соңгы казакъ әдәбиятының стиле Абайның аудиториягә, үзенең тыңлаучысына мөрәҗәгать итү традициясен алга таба да үстерә кебек. А. Байтурсынулы, М. Дулатов, Җ. Аймауытов, М. Жумабаев укучы һәм тамашачыга юнәлеш тотуның яңа формаларын эзли башлыйлар. Әйткәнебезчә, сәнгать социальлегенең эстетик принцибы Абай иҗатында ук ачыла. Социальлек аның поэзиядә үз чорының сәяси һәм дәүләт мәсьәләләрен яктыртуында чагыла. Элгәрләреннән аермалы буларак, Абай эстетиканың төп принцибын гамәлгә ашырган: сәнгатьтә шушы мизгелдәгене вакытта чикләнмәгән белән кушкан.

Абай беренче булып үз заманыңа туры килүнең аннан китүдә, аның мәшәкатьләренә баш-аягың белән чумуда түгел, ә реаль вазгыятькә һәм вакыйгаларга карашта ким дигәндә ике – шәхси һәм гомумкешелек, вакытлы һәм шул вакыттан тыш карашларны кушудан гыйбарәт булуын күрсәтте. Классик авторлар барысы да бу фикер яклы. Алар барысы да юкка гына үзләре исән вакытта ук танылу алмаган: Гете, Петрарка, Абай... Абайның шигырьләре телдән-телгә күчкән, җырлары (шул исәптән Татьянаның хаты) бөтен далага таралган.

Бу очракта уңышлы шигъри язмыш нәтиҗәсе турында сүз бармый, әмма бу – шагыйрьнең үз чорына аеруча туры килүе билгесе. Абай классик стиленең үлчәме неоклассиклыкка кире кайтырга чакырмый, әмма милли сәнгать стилен үстерүдә даими эшләүче актив башлангыч булып тора. А. Байтурсынулы билгеләп үткәнчә: «Заман бұрынғыдай болса, Абай алаштың атақты билерінің бірі болары шүбәсіз. Біліммен би болып, жұрт билейтін заман өтіп, тасың би болатын заманга қарсы туған. Білімі көптер жұрт билемей, малы көптер жұрт билейтін заманға қарсы туған» [Байтұрсынұлы, б. 156].

Совет әдәбияты тарихыннан без сәнгатькярнең сәнгатькә ике төрле мөнәсәбәттә булуын беләбез: хакимлек итүче власть идеологиясе предметы дип карау һәм сәнгатьне аның эстетик асылы итеп тану. Моннан сәнгать – чынбарлыкның түгел, ә тәҗрибәнең эстетик интерпретациясе дигән нәтиҗәгә киләбез. Тормышны үзенчәлекле рәвештә чагылдыручы әдәбият турында сүз бара, ул вакытта язучы, үзенең эчке бәйсезлеген саклап, чынбарлыкның объектив картинасын тудыра. Казакъ әдәбияты җәүһәрләренең күбесе, нинди генә хәлләр булуга карамастан, нәкъ менә шушы юнәлештә иҗат ителә. Абай исә казакъ әдәбиятында әдәбиятның ролен беренчеләрдән булып аңлаган әдип булды.

Абай бәхәс ителмәслек хакыйкатьне җиткерүдән бигрәк, бөтенләй башка, шундук аңлашылып бетми торган нәрсәләр турында сөйләве белән сокландыра. Аның рухи энергиясе, өзлексез эшләүче, яңадан-яңа һәм нәтиҗәле концепцияләр тудыручы фикер көче ташып тора. Мөгаен, бу – казакъ классик стиленең үзгә сыйфатыдыр да. Иң мөһиме – рухи сәламәтлек, яхшылык һәм явызлык турындагы төшенчәләрнең үзгәрешсез калуы. Мондый сораулар заманча түгелме?

Без әлеге «мәңгелек» хакыйкатьләргә җавап эзләп, Абай мирасына мөрәҗәгать итмибезме?

Шул ук вакытта Абай үзенең бу хакыйкатьләрне беренче булып ачуы турында сөйләми. Иң мөһиме шунда ки, безнең әйләнә-тирәбездә әзер җаваплар юк, без үзебез үз юлыбызны үзебез үтәргә һәм, безнең аңа мөнәсәбәтебезгә бәйсез рәвештә, күптән булган һәм эшләгән нәрсәләрне аңларга тиеш. *Без – бар итүчеләр түгел, ә булдырылган әйберләр буенча дөньяны танып белүчеләр генә. Без – мәхәббәт һәм гаделлек хезмәтчеләре. Һәм бер-беребездән Аллаһы Тәгалә бар иткәнне никадәр яхшырак аңлавыбыз белән генә аерылып торабыз...* [Абай, 1994]. Классик әдәбиятның мәңгелек заманчалыгының сере әнә шунда.

**Әдәбият**

*Байтұрсынұлы А.* 5 томдық шығармалар жинағы. 1 т. Алматы: Алаш, 2003.

Теория литературных стилей. Типология стилевого развития нового времени. Классический стиль. Соотношение гармонии и дисгармонии в стиле. М.: Наука, 1976.

*Тынянов Ю.Н.* Пушкин и современники. М., 1969.

*Исмакова А.* Открытие эстетического треугольника «автор-герой-читатель» в «Ғаклия» // Казахская художественная проза. Поэтика, жанр, стиль. Алматы: Наука, 1998.

*Абай.* Шығармалар. Алматы, 1994.

***Исмакова Айгөл Серик кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*М.О. Ауэзов исемендәге Тел һәм сәнгать институтының*
*бүлек мөдире (Казакъстан)*